ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-15, факс:2-80-13, e-mail: jutazaik@mail.ru, adm_jutaza@mail.ru, www. jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«___» ________ 20__ел** **№ _____**

«2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы халкының 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты проектын гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 06.10.2003 елның 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 елның 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 28.04.2020 елның №18 санлы карары белән кабул ителгән, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 04.10.2018 елның № 33 санлы карары белән кабул ителгән, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Гавами тыңлаулар уздыру инициаторы - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы.

3. Түбәндәгене билгеләргә:

- үткәрү вакыты: 2024 елның 25 ноябрендә 14 сәгать 00 минут;

- үткәрү урыны: Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Урыссу ш. т. б., Пушкин ур., 38 йорт, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының утырышлар залы;

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла торган адрес: Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы,

Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе, Пушкин ур., 38 йорт, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты.

4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

5. «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты турында»Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру буенча кушымта нигезендә оештыру комитеты (эшче төркем) составын расларга.

6. «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советы Карары проектын Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Ютазы муниципаль районы
Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин

Сучкова А.В.
8(85593)2-80-12

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгының
__________ 2024 ел № ______
карарына кушымта

«2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү буенча оештыру комитеты (эшче төркеме) составы

| | |
|---|---|
| Самонина С.П. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, оештыру комитеты (эшче төркем) рәисе |
| Әминова З.З. | Татарстан Республикасы Ютазы район Советының җирлекләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе, оештыру комитеты (эшче төркем) секретаре (килешү буенча) |
| Оештыру комитеты (эшче төркем) әгъзалары | |
| Мөхәммәтова Р.Г. | Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Галиев С.Ә. | Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2 нче Бәйрәкә сайлау округы депутаты, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясе Рәисе |
| Хисмәуллин Р.В. | Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 10 нчы Техснаб сайлау округы депутаты, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча Даими комиссиясе рәисе урынбасары |
| Якупов Р.М. | Татарстан Республикасы Ютазы район Советының юридик бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Ямалетдинов Ә.Ә. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе (килешү буенча) |